КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 март г.Казань № 115

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 6 май, 263 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 6 май, 263 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан 1995 елның 4 декабрендә расланган 13-7-2/469 номерлы Биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итүнең ветеринария-санитария кагыйдәләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Биологик калдыкларны күчерү, саклау, эшкәртү һәм утильләштерүнең ветеринария кагыйдәләрен раслау» 2020 ел, 26 октябрь, 626 нчы боерыгы белән расланган Биологик калдыкларны күчерү, саклау, эшкәртү һәм утильләштерүнең ветеринария кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Әлеге Тәртиптә түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

файдаланылмый торган хайван каберлеге (биотермик чокыр) – соңгы тапкыр күмү вакыты кимендә ике ел тәшкил иткән, аның ветеринария-санитария куркынычсызлыгы эпизоотологик һәм лаборатор-бактериологик тикшеренүләр нигезендә билгеләнгән хайван каберлеге (биотермик чокыр);

файдаланылмый торган хайван каберлеген (биотермик чокырны) бетерү – мичләрдә (крематорларда, инсинераторларда) яки ачык һавада траншеяләрдә (чокырларда) янмый торган калдык барлыкка килгәнгә кадәр яндыру яисә бетерелә торган хайван каберлегенең (биотермик чокырның) гуммиләштерелгән калдыгын муниципаль районнарның һәм «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 21 апрель, б-620 нче боерыгы белән расланган дәүләт вәкаләтләре бирелгән Түләмәле хайван каберлекләре һәм биотермик чокырлар исемлегенә (алга таба – Хайван каберлекләре (биотермик чокырлар) исемлеге) кертелгән, төзелеше һәм файдалануга тапшырылуы 2020 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлгә ашырылган башка хайван каберлегенә (биотермик чокырга) күчерү һәм яңадан күмү, шулай ук файдаланылмый торган хайван каберлекләре (биотермик чокыр) конструкцияләрен дезинфекцияләү һәм сүтү, барлыкка килгән чокырларны һәм траншеяләрне туфрак белән күмү, алга таба туфракның өске катламын тигезләү, китерү, профилактик дезинфекцияләү юлы белән уртача куркыныч биологик калдыкларны утильләштерү чаралары комплексы (чаралар).

Әлеге Тәртип максатлары өчен «биологик калдыклар» һәм «уртача куркыныч биологик калдыклар» төшенчәләре Ветеринария кагыйдәләрендә билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Әлеге Тәртип файдаланыла торган хайван каберлекләренә (биологик чокырларга), шулай ук, срокларының күптәнге булуларына карамастан, Ветеринария кагыйдәләренең 4 нче пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән терлекләр авыруларын кузгатучылар белән контаминацияләнгән һәм (яки) инфекцияләнгән биотермик калдыклар күмелгән терлек каберлекләренә (биотермик чокырларга) карата кулланылмый.»;

2.1 пунктта «Татарстан Республикасының бюджет ветеринария учреждениеләре» сүзләрен «ветеринария оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ветеринария идарәсенең ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария оешмаларының ветеринария өлкәсендәге белгечләре – кимендә 2 әгъза;»;

3.6 пунктта «1.9 пунктында» сүзләрен «4 пунктындагы икенче абзацында» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Файдаланылмый торган хайван каберлекләренең (биотермик чокырларның) туфрагын һәм гуммиләштерелгән калдыгын эпизоотологик һәм лаборатор-бактериологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә Ветеринария кагыйдәләренең 4 нче пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән хайваннар авыруларын кузгатучылар булуы ачыкланган очракта, мондый авыруларның чыганакларын бетерү чаралары «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 17 статьясында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

3.8 пунктта «Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт бюджет ветеринария учреждениесе» сүзләрен «ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) бетерү Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы милкендәге файдаланылмый торган хайван каберлеген (биотермик чокырны) исәптән чыгару турындагы боерыгы басылып чыкканнан соң тугыз айдан да соңга калмыйча түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

мичләрдә (крематорларда, инсинераторларда) яки ачык һавада траншеяләрдә (чокырларда) янмый торган калдыклар барлыкка килгәнгә кадәр яндыру юлы белән уртача куркыныч биологик калдыкларны утильләштерү;

бетерелә торган хайван каберлегенең (биотермик чокырның) гуммиләштерелгән калдыгын 2020 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) төзелеше һәм файдалануга тапшырылуы гамәлгә ашырылган хайван каберлекләре (биотермик чокырлар) исемлегенә кертелгән башка хайван каберлегенә (биотермик чокырга) күчерү һәм яңадан күмү;

җир өсте тигезлегеннән югарырак урнашкан конструкцияләрне дезинфекцияләү һәм сүтү (төрле материалларны каты коммуналь калдыклар полигоннарына чыгару, янгынга каршы куркынычсызлык чараларын үтәп, урында агач конструкцияләрне яндыру юлы белән);

хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) һәм траншеяләрне туфрак белән күмү, алга таба туфракның өске катламын тигезләү, китерү, профилактик дезинфекцияләү.

Көл һәм башка янмый торган калдыклар биологик калдыклар яндырылган шул ук траншеядә (чокырда) күмелергә тиеш.

Дезинфекция Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 2002 елның 15 июлендә расланган 13-5-2/0525 номерлы Дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларында дезинфекцияләү һәм дезинвазияләү кагыйдәләре нигезендә үткәрелә.»;

5.3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет ветеринария учреждениеләренең ветеринария белгечләре» сүзләрен «дәүләт ветеринария оешмаларының ветеринария өлкәсендәге белгечләре» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин